Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районының Белкино авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Белкино авыл җирлеге
Чертово торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

28 ноябрь, 2019 ел № 1

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Белкино авыл җирлегенең Чертово торак пунктында 2019 елның 28 ноябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 34 (утыз дүрт).

- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 22 (егерме ике).

- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 22 (егерме ике).

- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 0 (ноль).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез 2020 елда Питрәч муниципаль Белкино авыл җирлегенең Чертово торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, I төркем инвалидларыннан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау»

**кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Белкино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Белкино авыл җирлеге башлыгы А.Н. Меньшов